МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО - КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ

№ _____79/о_____

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

«__20___»_______01_______2026__

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Рәсәй Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының “Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү турында” 20.06.2025 ел, № 771/о боерыгы белән, 30.10.2025 елдан 20.11.2025 елга кадәр уздырылган гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмәне һәм бәяләмәне исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Карата авыл җирлегенең кушымта итеп бирелә торган генераль планын расларга.

2. Территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсенең көньяк-көнбатыш районнарны үстерү бүлегенә (А. С. Харитоновка):

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрү;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыру;

әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып биш эш көне эчендә “Роскадастр” җәмгыяти-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына торак пунктлар чикләре урнашу урынының график тасвирламасын һәм күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең координаталары исемлеген үз эченә алган торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләрне электрон рәвештә җибәрү;

әлеге боерыкны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында аны бастырып чыгару датасыннан 10 календарь көннән артмаган чорда урнаштыру;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыру.

3. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А. Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары Отдел контроля исполнения документов В.Н. Кудряшев

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-
коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының
20.01.2026__№_79/о___ боерыгы
белән расланды__

# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлегенең генераль планы

# ПРОЕКТ СОСТАВЫ

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы  Иске Карата авыл җирлегенең генераль планы

| № т/с | Исем | № бит/битләр | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| | **1 Том Генераль план** | | |
| | Текст материаллары | | |
| 1 | Территориаль планлаштыру турында нигезләмә | 11 | |
| | График материаллар | | |
| 2 | Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы М1: 10000 | 1/1 | территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәгә кушымталарны карарга |
| 3 | Торак пунктлар чикләре картасы (шул исәптән төзелеп килүче торак пунктлар чикләре картасы) М1: 10000 | 2/1 | |
| 4 | Функциональ зоналар картасы М1:10000 | 3/1 | |
| 5 | Торак пунктлар чикләре турында белешмәләр | 15 | |
| | **2 Том Генераль планны нигезләү буенча материаллар** | | |
| | Текст материаллары | | |
| 1 | Аңлатма язуы | 71 | |
| 2 | Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм территорияне инженерлык әзерлеге буенча чаралар, гражданнар оборонасы буенча чаралар, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чаралар исемлеге. Аңлатма язуы | 153 | |
| | График материаллар | | |
| 3 | Җирлек территориясеннән хәзерге заман файдалану картасы М1:10000 | 1/1 | генераль планны нигезләү материалларының аңлатма язмасына кушымталарны карарга |
| 4 | Инженерлык инфраструктурасы картасы М1: 10000 | 2/1 | |
| 5 | Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр, гражданнар оборонасы чаралары картасы М1: 10000 | 3/1 | Карарга: Генераль планны нигезләү материалларының «Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм территорияне инженерлык әзерләү чаралары, Гражданнар оборонасы чаралары, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге» аңлатма язуына Кушымталар |
| 6 | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (гамәлдәге урыны) М1:10000 | 4/1 | |
| 7 | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (проект тәкъдиме) М1:10000 | 5/1 | |

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ Әлки МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ХУРАДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ

**Территориаль планлаштыру турында нигезләмә**

**1 Том**

2026

# ЭЧТӘЛЕК

1. СВЕДЕНИЯ О ВИДАХ, НАЗНАЧЕНИИ И НАИМЕНОВАНИЯХ ПЛАНИРУЕМЫХ ДЛЯ РАЗМЕЩЕНИЯ ОБЪЕКТОВ МЕСТНОГО ЗНАЧЕНИЯ, ИХ ОСНОВНЫЕ ХАРАКТЕРИСТИКИ, ИХ МЕСТОПОЛОЖЕНИЕ, А ТАКЖЕ ХАРАКТЕРИСТИКИ ЗОН С ОСОБЫМИ УСЛОВИЯМИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ТЕРРИТОРИЙ В СЛУЧАЕ, ЕСЛИ УСТАНОВЛЕНИЕ ТАКИХ ЗОН ТРЕБУЕТСЯ В СВЯЗИ С РАЗМЕЩЕНИЕМ ДАННЫХ ОБЪЕКТОВ ........ 3

2. ПАРАМЕТРЫ ФУНКЦИОНАЛЬНЫХ ЗОН ........ 7

3. ПРИЛОЖЕНИЯ ........ 10

| № т/с | Объект исеме | Урнашу урыны | Объектның статусы (урнаштыруга яисә реконструкцияләүгә планлаштырыла торган) | Төп характеристикалар | Гамәлгә ашыру сроклары | | Территориядән файдаланунын махсус шартлары булган зоналар | Функциональ зона исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Беренче чират | Хисап срогы | | |
| **1** | **Социаль инфраструктура объектлары** | | | | | | | |
| 1.1 | Балалар бакчасы | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 80 урын | + | - | билгеләнми | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 1.2 | Гомуми белем бирү мәктәбе | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 100 укучы | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.3 | Спорт заллары булган спорт комплексы | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | Идән мәйданы 716 кв. метр | + | - | билгеләнми | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 1.4 | Проектлана торган мәктәп каршындагы спорт залы | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | Идән мәйданы 162 кв. метр | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.5 | Яссылыклы спорт корылмалары | Иске Карата авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 2000 кв.м | + | - | билгеләнми | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 1.6 | Яссылыклы спорт корылмалары | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 3357 кв.м | + | - | билгеләнми | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| **2** | **Транспорт инфраструктурасы объектлары** | | | | | | | |
| 2.1 | Автомобиль юлы «Чистарту корылмаларына керү юлы» | Иске Карата авыл җирлеге | урнаштыру планлаштырыла торган | 0,819 км** | + | - | билгеләнми | - |
| 2.2 | Автомобиль юлы «Зиратка керү юлы» | Иске Карата авыл җирлеге | урнаштыру планлаштырыла торган | 0, 847 км** | + | - | билгеләнми | - |
| 2.3 | «Түбән Колчура - Сиктерме» автомобиль юлы | Иске Карата авыл җирлеге | Реконструкцияләүгә планлаштырыла торган | 0,041 км** | + | - | билгеләнми | - |
| 2.4 | Автомобиль юлы «Торак комплексына керү юлы» | Иске Карата авыл җирлеге | Реконструкцияләүгә планлаштырыла торган | 0,181 км** | + | - | билгеләнми | - |

| № т/с | Объект исеме | Урнашу урыны | Объектның статусы (урнаштыруга яисә реконструкцияләүгә планлаштырыла торган) | Төп характеристикалар | Гамәлгә ашыру сроклары | | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар | Функциональ зона исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Беренче чират | Хисап срогы | | |
| 2.5 | Автомобиль юлы «Зиратка керү юлы» | Иске Карата авыл җирлеге | Реконструкцияләүгә планлаштырыла торган | 0,396 км** | + | - | билгеләнми | - |
| 2.6 | Урам-юл челтәре | Сиктерме авылы | Реконструкцияләүгә планлаштырыла торган | 4,3 км | + | + | билгеләнми | - |
| 2.7 | Урам-юл челтәре | Иске Карата авылы | Реконструкцияләүгә планлаштырыла торган | 2,2км | + | + | билгеләнми | - |
| **3** | **Инженерлык инфраструктурасы объектлары** | | | | | | | |
| 3.1 | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Иске Карата авыл җирлеге, Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1,3 км | + | + | санитар-яклау полосасы диаметрына карап кимендә 10 м | - |
| 3.2 | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Иске Карата авыл җирлеге, Иске Карата авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 2,9 км | + | - | санитар-яклау полосасы диаметрына карап кимендә 10 м | - |
| 3.3 | Су терәү һәм су басымы гидротехник корылмалары | Иске Карата авыл җирлеге, Сиктерме авылы | Реконструкцияләүгә планлаштырыла торган | 0,764 км | + | - | санитар-яклау полосасы диаметрына карап кимендә 10 м | - |
| 3.4 | Балалар бакчасы өчен блок-модульле котельная | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1 данә | + | - | билгеләнми | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 3.5 | Гомуми белем бирү мәктәбе өчен блок-модульле котельная | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1 данә | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 3.6 | Спорт комплексы өчен блок-модульле котельная | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1 данә | + | - | билгеләнми | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 3.7 | Газны редукцияләү пункты | Иске Карата авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1 данә | + | - | саклау зонасы - 10 м | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 3.8 | Газны редукцияләү пункты | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 5 данә | + | - | саклау зонасы - 10 м | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |

| № т/с | Объект исеме | Урнашу урыны | Объектның статусы (урнаштыруга яисә реконструкцияләүгә планлаштырыла торган) | Төп характеристикалар | Гамәлгә ашыру сроклары | | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар | Функциональ зона исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Беренче чират | Хисап срогы | | |
| 3.9 | Югары һәм түбән басымлы газ белән тәэмин итү челтәрләре | Иске Карата авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1,282 км | + | - | саклау зонасы - 2 м | - |
| 3.10 | Югары һәм түбән басымлы газ белән тәэмин итү челтәрләре | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 2,0 км | + | - | саклау зонасы - 2 м | - |
| 3.11 | ТП 6/0,4 кВ | Иске Карата авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1/203,79 объект/кВА | + | - | саклау зонасы - 10 м | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 3.12 | ТП 6/0,4 кВ | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 6/1201,92 объект/кВА | + | - | саклау зонасы - 10 м | Шәхси торак йортлар төзү зонасы |
| 3.13 | 0,4 кВ һава электр линиясе | Иске Карата авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 1,348 км | + | - | саклау зонасы - 2 м | - |
| 3.14 | 0,4 кВ һава электр линиясе | Сиктерме авылы | урнаштыру планлаштырыла торган | 2,6 км | + | - | саклау зонасы - 2 м | - |
| 3.15 | Канализация чистарту корылмалары | Иске Карата авыл җирлеге | урнаштыру планлаштырыла торган | 1000 $м^3$/тәүлек | + | - | саклау зонасы - 300 м | Инженерлык инфраструктурасы зонасы |
| 3.16 | Үзйөрешле канализация | Иске Карата авыл җирлеге | урнаштыру планлаштырыла торган | 2,106 км | + | - | саклау зонасы - 3 м | - |
| **4** | **Гомуми файдаланудагы яшелләндерү** | | | | | | | |
| 4.1 | Гомуми файдаланудагы яшелләндерү | Иске Карата авыл җирлеге торак пунктлары | урнаштыру планлаштырыла торган | 12,36 га | + | + | - | Гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы (урман парклары, парклар, бакчалар, скверлар, бульварлар, шәһәр урманнары) |

**Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын реконструкцияләү һәм урнаштыру (торак пунктлардан читтә) югарырак дәрәҗәдәге документларда исәпкә алынганнан соң мөмкин.

# 2. ФУНКЦИОНАЛЬ ЗОНАЛАРНЫҢ ПАРАМЕТРЛАРЫ

| № т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 701010101 | Шәхси торак йортлар төзү зонасы | планлаштырыла торган | Шәхси торак йортлар төзү зонасы күбесенчә шәхси торак йортлар, блокланган торак йортлар һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә һәм мәдәни-көнкүреш, коммуналь, социаль хезмәт күрсәтүнең беренчел баскычында, шулай ук тиешле инженерлык һәм транспорт инфраструктурасында тиешле объектлар төзү өчен каралган. | 102,5682 | 1.Балалар бакчасы<br>2.Яссылыклы спорт корылмалары<br>3. Спорт заллары булган спорт комплексы<br>4. Газны редукцияләү пункты<br>5. Трансформатор подстанциясе<br>6. Балалар бакчасы, спорт комплексы өчен блок-модульле котельныйлар. |
| | | | | | 115,5658 | гамәлдәге |
| 2 | 701010102 | Аз катлы торак йортлар төзү зонасы (мансардны да кертеп, 4 катка кадәр) | гамәлдәге | Аз катлы торак йортлар (мансардны да кертеп, биеклеге 4 катка кадәр булган күпфатирлы йортлар), блокланган төзелеш йортлары, шәхси торак йортлар һәм мәдәни-көнкүреш, коммуналь һәм социаль хезмәт күрсәтүнең беренчел баскычы объектлары, шулай ук тиешле инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы төзү өчен каралган. | 0,7090 | - |
| 3 | 701010301 | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона | гамәлдәге | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасының янәшәдәге объектларын урнаштырып, эшлекле, иҗтимагый, коммерция һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, шулай ук җитештерү һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектлар төзү өчен каралган | 0,2419 | - |

| № т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | 701010302 | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы | гамәлдәге | Башлыча социаль билгеләнештәге объектлар, шул исәптән мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, гомуми белем бирү оешмаларының, өстәмә белем бирү оешмаларының аерым объектлары, һөнәри һәм югары белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы объектлар, девиант тәртипле укучылар өчен махсус укыту-тәрбия учреждениеләре объектлары, фәнни оешмалар, мәдәният һәм сәнгать, сәламәтлек саклау, социаль билгеләнештәге объектлар, физик культура һәм массакүләм спорт объектлары төзү өчен билгеләнгән, инженерлык һәм транспорт белән тәэмин итүнең яңәшәдәге объектларын урнаштырып, гыйбадәт кылу бинаалары һәм корылмалары белән | 17,3920 | 1. Гомуми белем бирү мәктәбе<br>2. Проектлана торган мәктәп каршындагы спорт залы<br>3. Гомуми белем бирү мәктәбе өчен блок-модульле котельная |
| 5 | 701010402 | Коммуналь-склад зонасы | гамәлдәге | Йөкләрне вакытлыча саклау, бүлү һәм күчереп төяү (стратегик запасларны саклаудан тыш) билгеләнешендәге, йөк төзелгән җитештерү комплексларының өлешләре булмаган корылмаларны урнаштыру өчен билгеләнгән: сәнәгать базалары, складлар | 4,4383 | - |
| 6 | 701010404 | Инженерлык инфраструктурасы зонасы | гамәлдәге | Инженерлык инфраструктурасы зонасы башлыча су белән тәэмин итү объектларын, су агызу объектларын, җылылык белән тәэмин итү объектларын, газ белән тәэмин итү объектларын, электр белән тәэмин итү объектларын, элемтә объектларын, башка төр инженерлык инфраструктурасын, шул исәптән коммуникацияләрне үткәрү коридорларын урнаштыру өчен каралган | 4,3163 | - |
| | | | планлаштырыла торган | | 2,9129 | 1. Канализация чистарту корылмалары |
| 7 | 701010405 | Транспорт инфраструктурасы зонасы | гамәлдәге | Транспорт инфраструктурасы зонасы башлыча автомобиль транспорты объектларын, тимер юл транспорты объектларын, һава транспорты объектларын, су транспорты объектларын, торба үткәргеч транспорты объектларын, башка төр транспорт инфраструктурасы объектларын, урам-юл челтәре объектларын һәм аларга бәйле объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән | 14,2169 | - |
| | | | планлаштырыла торган | | 0,4942 | - |
| 8 | 701010501 | Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы | гамәлдәге | Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы авыл хуҗалыгы җирләрендә авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүгә, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтүгә бәйле хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен каралган. | 3654,3034 | - |
| | | | планлаштырыла торган | | 0,9345 | |

| № т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | 701010503 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитештерү зонасы | гамәлдәге | Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитештерү зонасы авыл хуҗалыгы җитештерүе объектларын, агросәнәгать комплексына хезмәт күрсәтү объектларын, шулай ук инженерлык һәм транспорт инфраструктурасының янәшәдәге объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән | 47,9221 | - |
| | | | планлаштыры ла торган | | 16,1418 | - |
| 10 | 701010601 | Гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы (урман парклары, парклар, бакчалар, скверлар, бульварлар, шәһәр урманнары) | планлаштыры ла торган | Гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы (урман парклары, парклар, бакчалар, скверлар, бульварлар, шәһәр урманнары) шәһәр паркларын, скверларын, бакчаларын, бульварларын, яр буйларын, шәһәр урманнарын, территорияне төзекләндерү, яссы спорт корылмаларын урнаштыру өчен билгеләнгән яшел утыртмаларны урнаштыру өчен билгеләнгән | 12,3560 | - |
| 11 | 701010605 | Урман зонасы | гамәлдәге | Урман зонасы дәүләт урман фонды җирләрен һәм башка категориядәге җирләрдә урнашкан урман кишәрлекләрен урнаштыру өчен билгеләнгән | 978,5504 | - |
| 12 | 701010701 | Зиратлар зонасы | гамәлдәге | Зиратлар зонасы зиратлар, крематорийлар һәм күмү урыннары, шулай ук тиешле гыйбадәт корылмалары урнаштыру өчен билгеләнгән | 5,9402 | - |
| 13 | 701010702 | Калдыкларны туплау һәм күмү зонасы | гамәлдәге | Калдыкларны җыю һәм күмү зонасы җитештерү һәм куллану калдыкларын, биологик калдыкларны урнаштыру, саклау, күмү, утильләштерү, туплау, эшкәртү, зарарсызландыру өчен билгеләнгән | 0,0945 | - |
| 14 | 701010900 | Акваторияләр зонасы | гамәлдәге | Акваторияләр зонасы табигый яисә ясалма сулык, су агымы яки суларның даими яисә вакытлыча тупланышы характерлы формаларга һәм су режимы билгеләренә ия булган башка объекттан гыйбарәт. | 44,5281 | - |
| 15 | 701010703 | Махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр зонасы | планлаштыры ла торган | Махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр зонасы санитар-яклау, су саклау, яклау-мелиорация зоналарының яшелләндерелгән территорияләрен, автомобиль һәм тимер юллар буенда утыртмаларны, махсус билгеләнештәге башка яшелләндерелгән территорияләрне урнаштыру өчен билгеләнгән | 0,9887 | 1. Урман парклары<br>2. Парклар<br>3. Бакча<br>4. Скверлар<br>5. Бульварлар<br>6. Шәһәр урманнары |

# 3. КУШЫМТАЛАР

**1 нче кушымта.** Генераль план материаллары карталар рәвешендә.

**1.1 нче кушымта**

Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы М1: 10000.

**1.2 нче кушымта**

Торак пунктларның чикләре (шул исәптән барлыкка килә торган торак пунктларның чикләре) картасы М1:10000.

**1.3 нче кушымта**

Функциональ зоналар картасы М1: 10000.

## ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН СТАРОХУРАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
## КАРТА ПЛАНИРУЕМОГО РАЗМЕЩЕНИЯ ОБЪЕКТОВ МЕСТНОГО ЗНАЧЕНИЯ
М 1:10000



# ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН СТАРОХУРАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## КАРТА ГРАНИЦ НАСЕЛЕННЫХ ПУНКТОВ (В ТОМ ЧИСЛЕ ГРАНИЦ ОБРАЗУЕМЫХ НАСЕЛЕННЫХ ПУНКТОВ)

М 1:10000






## ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН СТАРОХУРАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

КАРТА ФУНКЦИОНАЛЬНЫХ ЗОН

М 1:10000

